РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

01.09.2026 Буа шәһәре № 305/Бк/к

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы мәгариф учреждениеләрен төзү, үзгәртеп оештыру һәм бетерү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2015 елның 07 июлендәге 368-п номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Муниципаль хокукый актны «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 102 статьясындагы 3 өлешенә туры китерү максатларында (25.04.2026 ред.), Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының 2023елның 06 апрелендәге 240 номерлы боерыгы белән расланган Башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү мәгариф программалары буенча укучыларны күчерүне гамәлгә ашыру тәртибе һәм шартлары, Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының 2024 елның 09 декабрендәге 862 номерлы карары белән расланган, Мәктәпкәчә белем бирүнең уку-укыту программалары буенча укучыларны күчерүне гамәлгә ашыру тәртибе һәм шартлары нигезендә Буа муниципаль районы башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы мәгариф учреждениеләрен төзү, үзгәртеп оештыру һәм бетерү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2015 елның 07 июлендәге 368-п номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «Муниципаль мәгариф учреждениеләрен үзгәртеп оештыру һәм бетерү» 3 бүлегенә түбәндәге эчтәлекле 3.4.1 һәм 3.4.2 пунктлар өстәргә:

«3.4.1. Муниципаль мәгариф учреждениесен мәҗбүри тәртиптә үзгәртеп оештыру яисә бетерү турында гамәлгә куючы карарында тиешле дәрәҗәдәге һәм юнәлештәге белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы кабул итүче оешмаларның исемлеге билгеләнә, аларда күчүгә язмача ризалык биргән укучылар күчерелә.

3.4.2. Балигъ булган белем алучыларны күчерү – аларның язма ризалыгы белән, ә балигъ булмаган белем алучыларны күчерү - аларның ата-аналарының (законлы вәкилләренең) язма ризалыгы белән гамәлгә ашырыла. Белем алучының (аның ата-анасының яисә законлы вәкилләренең) тәкъдим ителә торган кабул итүче оешмага күчерүдән баш тартуы гамәлгә куючыны әлеге затларның мәгариф турындагы законнар нигезендә белем алу хокукын гамәлгә ашыруны тәэмин итү бурычыннан азат итми».

1.2. 3 нче бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 3.14.1 яңа пункт өстәргә:

«3.14.1. Муниципаль мәгариф учреждениесе бетерелгәндә аның мөлкәте, кредиторларның таләпләре канәгатьләндерелгәннән соң, мәгариф учреждениесе уставы нигезендә мәгарифне үстерү максатларына җибәрелә».

2. Әлеге карар басылып чыккан вакыттан законлы көченә керә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru/), шулай ук Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында (http://buinsk.tatarstan.ru) урнаштырылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары – «Буа муниципаль районы мәгариф идарәсе» МКУ башлыгы Н.А.Македонскаяга йөкләргә.

Буа муниципаль районы Башкарма
комитеты җитәкчесе Л.Р. Шакирҗанов